КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2025 ел, 20 март г.Казань № б-593

2025 елда Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итү һәм Россиядә һәм Татарстан Республикасында Ватанны саклаучылар елын уздыру кысаларында:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына:

2025 елның 19 апрелендә урман фонды территориясендә «Хәтер бакчасы» халыкара акциясен (алга таба – Акция) үткәрүне оештырырга;

тиешле эшләрне башлап җибәрү алдыннан хезмәт иминлеге буенча максатчан инструктажны мәҗбүри үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, мәгариф оешмаларының чыгарылыш укучылары белән берлектә, Акция үткәрү мөмкинлеген карарга.

3. Республика башкарма хакимият органнарына Акциядә катнашырга.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасының яшьләр иҗтимагый берләшмәләренә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә Акция үткәрүне оештыруны һәм анда катнашуны тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына массакүләм мәгълүмат чараларында Акцияне яктыртуны, шулай ук урманга карата сакчыл мөнәсәбәт турында материаллар бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.

6. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин